КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 12 июль г.Казань № 672

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасының истәлекле билгеләрен әзерләү һәм тарату белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 21 октябрь, 942 нче;

«Үткәрелә торган чараларның стиль бердәмлеген тәэмин итү максатларында, Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү кысаларында чараларның җаваплы башкаручыларының үзара хезмәттәшлеген оештыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 20 июль, 610 нчы;

«Россия Федерациясе төбәкләрендә (Татарстан Республикасыннан тыш) этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибен һәм Россия Федерациясе төбәкләрендә (Татарстан Республикасыннан тыш) этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү советы составын раслау хакында» 2021 ел, 11 сентябрь, 856 нчы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин